**Республика Татарстан**
**Руководитель Исполнительного комитета Бухарайского сельского поселения Заинского муниципального района**

Ул.Новая , д. 4, с.Бухарай,
Заинский район, 423536

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлегенең башкарма комитеты җитәкчесе**

Яңа урамы, 4 нче йорт,
Бохарай авылы, Зәй районы, 423536

Телефон, факс 67-7-34. Электронный адрес: Buhar.zai@tatar.ru, сайт: www.Buhar.ucoz.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«11» март 2019 ел** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органы төзү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органы төзү тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Бохарай авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшмә органы составын расларга (2 нче кушымта).
3. Карарны Бохарай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Бохарай авыл җирлегенең рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/rus/buharayskoe.htm) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Р.И. Нуриев**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Бохарай авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
«1[illegible]» мартындагы 06 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органы төзү ТӘРТИБЕ

### 1.Гомуми нигезләмәләр

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органы (алга таба - координация органнары) Бохарай авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру буенча килештерелгән гамәлләрне тәэмин итү максатларында төзелә.

Координация органнары җирле үзидарә органнары яки билгеле бер даирәдәгеләрнең бурычларын хәл иткәндә яки конкрет чаралар үткәрү өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциягә карамаган оешмалар инициативасы буенча төзелергә мөмкин.

Киңәшмә органнары советлар дип атала һәм мәсьәләләрне алдан карау һәм алар буенча рекомендация характерындагы тәкъдимнәр әзерләү өчен төзелә.

Төзелә торган совет яки комиссия бер үк вакытта координация органы да, киңәшмә органы да булырга мөмкин.

Координация органы төзү турында кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар мөрәҗәгать иткән очракта, җирле үзидарә органнары бер ай эчендә мондый коммерциячел булмаган оешмаларга кабул ителгән карар турында хәбәр итә. Координация органнары төзү өчен «Бохарай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге администрациясе нигезләмә проектын эшли, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- органның исеме һәм аны булдыруның максаты;
-рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип вазыйфасы билгеләнә;
- координация органнарының персональ составы билгеләнә;
-координация органнары рәисе һәм җаваплы сәркатибенең вәкаләтләре күрсәтелә;
- кирәк булганда, координация органнары төзү максатларына ирешүне тәэмин итә торган башка нигезләмәләр кертелә;
- нигезләмә “Бохарай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге администрациясе карары белән раслана;
- координацион органнар булдыру турында карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

Үз эшчәнлегендә координация органнары Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларына һәм күрсәтмәләренә, башка норматив хокукый документларга, шулай ук әлеге Тәртипкә таяна.

## 2. Координация һәм киңәшмә органының төп максатлары

Координация яисә киңәшмә органы түбәндәге максатларда оештырыла:

1. Бохарай авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының ролен арттыру;
2. Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче дәүләт хакимияте органнары һәм эшкуарлык субъектлары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыру өчен;
3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү өчен;
4. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары проблемаларын өйрәнү һәм гомумиләштерү, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өчен;
5. Җәмәгать оешмаларын, эшкуарлар берләшмәләрен, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен эшкуарлык эшчәнлегенә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга җәлеп итү һәм әлеге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен;
6. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативаларны күрсәтү һәм хуплау өчен;
7. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру өчен;
8. Бохарай авыл җирлеге администрациясе билгеләгән башка максатлар өчен.

## 3. Координация яисә киңәшмә органының составы

Координация яисә киңәшмә органы составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре, кече һәм урта бизнес вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре керә ала.

Координация яисә киңәшмә органының персональ составы һәм вәкаләтләре “Бохарай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге администрациясе карары белән раслана. Координация яисә киңәшмә органы рәисе булып координация яки киңәшмә органы төзелгән Бохарай авыл җирлеге администрациясе башлыгы тора.

## 4. Координация яисә киңәшмә органы эшчәнлеген тәэмин итү

Координация яки киңәшмә органы, әгәр аның утырышында аның әгъзаларының илле проценты катнашса, хокуклы була. Карала торган мәсьәлә буенча карар координация яки киңәшмә органы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Координация яки киңәш бирү органы эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү тиешле координация яисә киңәшмә органын булдырган Бохарай авыл җирлеге администрациясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Координацион яки киңәшмә органының эш регламенты аның утырышында раслана.

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Бохарай авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
«11» мартындагы 06 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Бохарай авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшмә органы составы**

1. Нуриев Ринат Илдар улы – координация советы рәисе – авыл җирлеге башлыгы, башкарма комитет җитәкчесе;
2. Миннекаева Олеся Николаевна – секретарь – башкарма комитет белгече;
3. Шиһабетдинова Лилия Рәвгать кызы – 2 нче номерлы сайлау округы депутаты;
4. Груздева Елена Владимировна – Бохарай авылы клуб мөдире (килешү буенча);
5. Галиуллин Гомәр Гамир улы – КФХ, 7 нче номерлы сайлау округы депутаты;